| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_____05.02.2021______ п.г.т.Алексеевское № _32___

**«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2013 елның 23 сентябрендәге 735 номерлы башкарма комитет карарына үзгәрешләр кертү хакында**

1. «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2013 елның 23 сентябрендәге 735 номерлы башкарма комитет карарына кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«һәм мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка түләүләре буенча бурычы булмаганда.»;

1.2. 2.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычы булмау турында белешмәләр Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында бирелә.»;

1.3. 2.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычы булу.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Симашевага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А.Гайнуллин**